**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР
**IV чакырылыш XII утырыш**

**16 август 2023 ел** **№ 40** **Урыссу штп**

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2022 елның 28 декабрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2022 елның 28 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә".

1.2. Нигезләмәнең 2 абзацы 3.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәр вазыйфасын түбәнәйтү белән ризалашмаган яисә аның ризалыгы белән муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчерү мөмкин булмаган очракта, яллаучы вәкиле (эш бирүче) аттестация үткән көннән алып бер айдан да артык булмаган вакыт эчендә аны биләгән вазыйфасына аттестация нәтиҗәләре белән расланган, квалификациясе җитәрлек булмау сәбәпле,

муниципаль хезмәттән азат итәргә мөмкин. Күрсәтелгән срок узганнан соң, муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү яисә аны шушы аттестация нәтиҗәләре буенча вазыйфасында түбәнәйтү рөхсәт ителми.».

1.3. Нигезләмәнең 3.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аттестация уздырганнан соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башлыгының хокукый акты басылып чыга. Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органы җитәкчесе муниципаль хезмәткәрнең:

1) вазыйфаи үсеш тәртибендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән тәртиптә кадрлар резервына кертелергә тиеш булуы;
2) бүләкләнергә тиешлеге;
3) һөнәри яңадан әзерләүгә, квалификация күтәрүгә яисә өстәмә һөнәри белем алуга юнәлдерелүе;
4) муниципаль хезмәт вазыйфасында түбәнәюе турында карар кабул итә”.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Рәсми Татарстан» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татартсан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы,
Ютазы район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин